КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 15 август г.Казань № 819

2021 ел йомгаклары буенча башкарма дисциплинаның, халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәүнең торышы турында

Башкарма дисциплинаны контрольдә тотуны һәм алга таба ныгытуны көчәйтү, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан халыкның тормыш сыйфатын һәм эшчәнлек нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары идарәсенә дәүләт йөкләмәсен үтәүне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына:

электрон рәвештә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында күрсәтелә торган барлык дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүнең сыйфаты күрсәткечләре буенча хисап белешмәләрен автоматлаштырылган формалаштыру механизмын эшләргә;

«Ачык Татарстан» мәгълүмат порталының «Ведомстволар хисаплары» бердәм дәүләт хисаплылыгы системасының тиешле хисапларга күрсәткечләрен квартал саен кертүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү

өлкәсендә стратегияне раслау турында» 2021 ел, 18 август, 748 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы икътисады, социаль өлкә һәм дәүләт идарәсе тармакларын цифрлы трансформацияләү өлкәсендә стратегиягә үзгәрешләр кертү буенча 2022 елның 29 августына кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гомумиләштерелгән тәкъдимнәр кертергә;

2022 елның 20 сентябренә кадәр Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алулар гамәлгә ашыру максатлары өчен чит дәүләтләрдән килә торган программа белән тәэмин итүгә кертүне тыю билгеләү турында» 2015 елның 16 ноябрендәге 1236 номерлы карары, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр чорга Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 2018 елның 7 маендагы 204 номерлы Указы таләпләрен үтәүне тәэмин итү планын тәкъдим итәргә, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарында эш урыннарын этаплап яңадан җиһазлауны һәм хезмәткәрләрне кирәкле укытуны күздә тотып;

мәгълүмат куркынычсызлыгы буенча алдагы эшне дәвам итәргә, Татарстан Республикасының киберкуркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб тәкъдимнәрен үтәүне тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү срокларын кыскарту һәм дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне реинжиниринг буенча эшне дәвам итәргә;

«Цифрлы трансформация (CDTO)» һөнәри әзерлек программасы буенча укыту барышында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан эшләнгән проектларны гамәлгә ашыру эшен дәвам итәргә;

2023 елның I кварталында Татарстан Республикасында Цифрлаштыру елына йомгак ясау буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте утырышы уздыруны оештырырга.

2. Россия Федерациясенең башка субъектлары белән чагыштырганда, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган күрсәткечләр үсешенең түбән темпларына күрсәтергә.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә Россия Федерациясе Президентының “Россия Федерациясе субъектларының иң югары вазыйфаи затлары

(дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында” 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы белән, шул исәптән 2022 ел нәтиҗәләре буенча аларның үсеш динамикасы буенча, билгеләнгән күрсәткечләрне үтәүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск, Биектау, Лениногорск, Бөгелмә һәм Теләче муниципаль районнары башлыкларына контроль юнәлешләрнең түбән дәрәҗәдә башкарылуын күрсәтергә һәм салымнар, җир һәм мөлкәтне арендалау бурычларын бетерү буенча чараларны үтәүне, юл хәрәкәте иминлеге буенча район комиссияләренең эшен шәхси контрольдә тотуны көчәйтергә тәкъдим итәргә. Кабул ителгән чаралар турындагы мәгълүматны 2022 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белән берлектә 2022 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән төзелергә, реконструкцияләнергә, капиталь ремонтланырга һәм (яки) төзекләндерелергә тиешле иҗтимагый инфраструктура объектлары исемлекләрен формалаштыруда катнашучылар хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2022 ел, 28 май, 493 нче карарына дәүләт (муниципаль) милкендәге файдаланылмый торган (өлешчә файдаланыла торган) мөлкәтне карау өлешендә Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән төзелергә, реконструкцияләнергә, капиталь ремонтланырга һәм (яисә) төзекләндерелергә тиешле җәмәгать инфраструктурасы объектлары исемлеген төзегәндә үзгәрешләр кертү кирәклеге турында килештерелгән тәкъдимнәр кертергә.

6. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә 2022 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына дәүләт (муниципаль) милкендәге файдаланылмый торган (өлешчә файдаланыла торган) мөлкәт өлешендә килештерелгән тәкъдимнәр кертергә:

дәүләт (муниципаль) учреждениеләре ихтыяҗлары өчен хуҗалык әйләнешенә җәлеп итү;

кече һәм урта эшкуарлык субъектларына һәм индивидуаль эшкуарлар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кулланучы физик затларга ташламалы шартларда бирү буенча.

7. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы» ассоциациясе белән берлектә 2022 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына авыл хуҗалыгы җирләрен хуҗалык әйләнешенә мөмкин кадәр күбрәк җәлеп итү, шул исәптән уңайсыз җирләрне урман фонды җирләре составына тапшыру, шулай ук авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне нигезсез ваклауга бәйле мәсьәләләр буенча килештерелгән тәкъдимнәр кертергә.

8. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән берлектә 30 көн эчендә мәгънәләрне төзәтү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тәкъдимнәр кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 – 2024 елларга Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре эшчәнлеге эффективлыгын һәм халыкның тормыш сыйфатын бәяләү индикаторларын раслау турында» 2022 ел, 23 март, 256 нчы карары белән расланган «Заявка хәл ителгән» статусы бирелгән «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кергән заявкалар өлеше» индикаторы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең планлаштырылган нәтиҗәлелек күрсәткечләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган «Заявка хәл ителгән» статусы бирелгән «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында бастырылган хәбәрнамәләр өлеше» нәтиҗәлеге күрсәткечләре.

9. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына:

даими нигездә законнар мониторингын һәм республика хокукый актларына тиешле үзгәрешләрне оператив кертүне тәэмин итәргә;

федераль законнарны бастырып чыгару (кабул итү) белән бәйле рәвештә бастырып чыгару (кабул итү) таләп ителә торган норматив хокукый актларны эшләүне һәм (яисә) басманы (кабул итүне) тәэмин итү өлешендә норма чыгару эшчәнлегенә контрольне федераль законнар рәсми басылып чыккан көннән соң өч ай эчендә көчәйтергә;

12 айдан артык башкарудагы йөкләмәләргә анализ ясарга, 2022 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына актуальлеген югалткан йөкләмәләрне үтәү һәм (яисә) контрольдән төшерү буенча тәкъдимнәр кертергә.

10. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының норма чыгару эшчәнлегенә контрольне көчәйтергә:

норматив хокукый актларны бастырып чыгаруны (кабул итүне) тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына норматив хокукый актлар проектларын кертү өлешендә Татарстан Республикасы законнары басылып чыгуга (кабул ителүгә) бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары басылып чыккан (кабул ителгән) көннән алып 60 көн эчендә бастырып чыгару (кабул итү) таләп ителә торган;

квартал саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 30 көненә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, дәүләт учреждениеләренә, җирле үзидарә

органнарына һәм муниципаль учреждениеләргә карата куелган мөлкәти булмаган характердагы таләпләр реестры белешмәләре нигезендә җыелма мәгълүматны тапшырырга.

11. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына, Татарстан Республикасының Туризм буенча дәүләт комитетына, «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча агентлыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсенә, Үзйөрешле машиналарның һәм техниканың башка төрләренең техник торышын күзәтү идарәсенә башкарма хакимият органы структурасын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартын раслау турында» 2008 ел, 07 апрель, 207 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органының үзәк аппараты структурасы стандартына туры китерергә.

12. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенең үтәлешенә аерым контроль урнаштырырга, шул исәптән җавапларның һәм мөрәҗәгать итүчеләргә белдерүләрнең юлламасын раслый торган мәгълүматны саклауны тәэмин итәргә.

Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча идарәсенә гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен бозу фактлары санын киметү максатларында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау мәсьәләсе буенча укыту семинарлары үткәрүне тәкъдим итәргә.

13. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары җитәкчеләренә үтәргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

дәүләт (муниципаль) хезмәтләре һәм ярдәм чаралары (грантлар, субсидияләр, башка түләүләр) күрсәткәндә, алучыларга Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурыч барлыгы (булмау) турында мәгълүмат бирергә;

Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетына салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны һәм бюджеттан тыш дәүләт социаль фондларына иминият кертемнәре буенча бурычларны кыскарту һәм аларның үсешен булдырмау максатларында адреслы эш буенча Федераль салым хезмәте идарәсе белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасында торак белән тәэмин итүдә гражданнарга дәүләт ярдәме» программасы турында» 2021 ел, 27 декабрь, 1293 нче карары белән расланган «2022 елга Татарстан Республикасында торак белән тәэмин итүдә гражданнарга дәүләт ярдәме» программасы буенча кабул ителгән йөкләмәләрнең үтәлешен тикшереп торуны тәэмин итәргә һәм 2022 елның 15 августына кадәр тиешле мәгълүматны Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына тапшырырга;

халык арасында электрон рәвештә хезмәтләр алуның өстенлеген аңлатуга юнәлдерелгән мәгълүмати эшне көчәйтергә, электрон рәвештә хезмәт күрсәтү күрсәткечен агымдагы ел ахырына кадәр кимендә 60 процентка җиткерергә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы эшчәнлеге кысаларында Татарстан Республикасы гражданнарының, дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының электрон хезмәттәшлеге турында” 2012 ел, 10 август, 676 нчы карары нигезендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау срокларын тикшереп торуны тәэмин итәргә, шулай ук мөрәҗәгатьләрдә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кабул ителә торган чараларның җаваплары һәм нәтиҗәлелеге сыйфатына аерым игътибар бирергә;

тиешле республика программаларын һәм чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль районнары, шәһәр округлары бюджетларын формалаштырганда «Халык контроле» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына керә торган гражданнарның мөрәҗәгатьләрендә күрсәтелгән мәсьәләләрне хәл итү өчен кирәкле чараларны күздә тотарга.

14. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты турындагы нигезләмәне законнар таләпләренә туры китерү, шулай ук аларның аерым нигезләмәләрен актуальләштерү кирәклеге максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсенә 2022 елның 15 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламентын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты - Татарстан Республикасы Хөкүмәте Аппараты турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2005 ел, 05 декабрь, 563 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары проектын эшләүне тәэмин итәргә.

15. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма хакимият органнарына, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, алар карамагындагы дәүләт учреждениеләренә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына, муниципаль учреждениеләргә карата дәгъвалау һәм административ таләпләрне судта карауда катнашуны әзерләүне һәм тәэмин итүне, шулай ук суд карарларына үз вакытында дәгъва белдерүне тикшереп торуны көчәйтергә;

мобилизацион әзерлек хәлен контрольдә тоту һәм комплекслы тикшерүләр барышында ачыкланган яшеренлек һәм мобилизацион әзерлек режимын оештырудагы җитешсезлекләрне, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда дәүләт хакимияте башкарма органнарында һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарында мобилизацион әзерлек йомгаклары һәм 2022 елга бурычлар турында» 2022 ел, 08 апрель, 02-340 номерлы карарына кушып бирелә торган мәгълүматка карата күрсәтелгән җитешсезлекләрне бетерү чараларын күрергә;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе белән берлектә 2022 елның 1 октябренә кадәр ведомство буйсынуындагы учреждениеләрнең эшчәнлеген ихтыяҗ предметына бәяләргә һәм

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына аларны оптимальләштерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарын минимальләштерү, җаваплылыкның төрле төрләренә җәлеп итү рәвешендә мөмкин булган хокукый нәтиҗәләрне төшереп калдыру максатларында:

мөлкәти булмаган характердагы таләпләрне үтәүгә аерым игътибар бирергә, шул исәптән республика һәм федераль программаларга тиешле чараларны кертү юлы белән;

башкарма производстволар кысаларында суд карарларын үтәүне тәэмин итәргә.

16. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Башкарма хакимият органнарының үзара хезмәттәшлеген координацияләү идарәсенә квартал саен, хисап чорыннан соңгы айның 15 көненә кадәр, Татарстан Республикасы Премьер-министрына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасарының һәм Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарларының контроль йөкләмәләрен үтәү турында мәгълүмат тапшырырга.

17. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2020 ел йомгаклары буенча башкарма дисциплинаның, халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәүнең торышы турында» 2021 ел, 23 апрель, 278 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 ел йомгаклары буенча башкарма дисциплинаның, халыкның тормыш сыйфатын һәм аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторлары буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарына идарә итүгә дәүләт йөкләмәсен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан үтәүнең торышы турында» 2021 ел, 23 апрель, 278 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 30 июнь, 521 нче.

18. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе Ш.Х.Гафаровка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин